# ПЕДАГОГИКА ҺӘМ ПСИХОЛОГИЯ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕН ЯКТЫРТКАН ТАТАР ЖУРНАЛЛАРЫ

**„Азат ханым“** — 1917—1918 елларда Астраханьда чыккан хатын-кызлар журналы; бала тәрбиясенә багышланган мәкаләләр дә басылган.

**„Азат хатын“** — Казанда 1926 елдан башлап чыгып килә торган хатын-кызлар журналы; педагогик мәкаләләр дә биреп бара.

**„Ак юл“** — 1913—1916 елларда Казанда басылган балалар журналы.

**„Акмулла“** — 1912—1914 елларда Троицк шәһәрендә басылган әдәби журнал; педагогика мәсьәләләрен дә яктырткан.

**„Атака“** — 1930—1932 елларда Казанда чыккан әдәби журнал, 1932 елдан „Совет әдәбияты“ исеме белән басыла башлады.

**„Аң“** — 1912—1918 елларда Казанда чыккан әдәби һәм фәнни-публицистик журнал, тәрбия мәсьәләләренә дә зур урын биргән.

**„Балалар дөньясы“** — 1917—1918 елларда Казанда чыгарылган балалар журналы.

**„Башлангыч мәктәп“** — 1936—1937 елларда Казанда „Мәгариф“ журналының дәвамы буларак чыккан, 1938 елдан „Совет мәктәбе“ исемендә басыла башлаган.

**„Икътисад“** — 1908—1913 елларда Самарада чыгарылган фәнни-публицистик журнал; иҗтимагый хәрәкәтләр турында материаллар бар.

**„Казан утлары“** — 1966 елдан Казанда чыгарылган әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал, 1930—1932 елларда „Атака“, 1932—1965 елларда „Совет әдәбияты“ исемендә чыккан, татар мәдәнияте һәм мәгарифе тарихыннан да мәкаләләр бастырып килә.

**„Карчыга“** — 1906—1907 елларда Оренбургта чыгарылган, бала тәрбиясенә караган мәкаләләр дә басылган.

**„Кечкенә иптәшләр“** — 1924—1928 елларда Мәскәүдә чыгарылган балалар журналы.

**„Колхоз яшьләре“** — 1925—1933 елларда Казанда басыла, яшьләрне тәрбияләү мәсьәләләрен киң яктырта.

**„Комвуз студенты“** — 1925—1929 елларда Казанда чыккан, яңа кеше тәрбияләү мәсьәләләрен киң яктырткан журнал.

**„Культура революциясе“** — 1931—1932 елларда Мәскәүдә чыккан фәнни-популяр журнал.

**„Кызыл шәрык“** — 1920—1922 елларда Казанда басыла, тәрбия мәсьәләләренә караган материалларны да биреп бара.

**„Мәгариф“** — 1921—1936 елларда Казанда Татарстан АССР Халык мәгарифе комиссариаты тарафыннан чыгарылган айлык педагогик журнал, 1937 елдан „Башлангыч мәктәп“ исемендә чыга башлаган.

**„Мәгариф эшләре“** — 1920 елда Стәрлетамакта басыла.
**„Мәгариф эшләре“** — 1928 елда Свердловскида чыга.
**„Мәгариф эшчесе“** — 1926—1931 еллард. Мәскәүдә чыккан педагогик һәм психологик журнал.
**„Мәгариф җитәкчесе“** — 1927—1928 елларда Оренбургта чыккан педагогик һәм психологик журнал.
**„Мәгълүмат“** — 1908—1917 елларда Уфада чыга.
**„Мәктәп“** — 1913—1914 елларда Казанда чыккан педагогик журнал.
**„Мәктәптә география“** — 1935 елда Казанда бер генә саны чыга.
**„Мөгаллим“** — 1913—1914 елларда Оренбургта укытучылар өчен чыгарыла.
**„Октябрь баласы“** — 1929—1932 елларда Мәскәүдә ВЛКСМ ҮК тарафыннан Муса Җәлил редакциясендә чыгарылган балалар журналы.
**„Октябрь яшьләре“** — 1924—1925 елларда Казанда басылган.
**„Пионер“** — 1952—1956 елларда Казанда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан чыгарылган балалар журналы, 1957 елдан „Ялкын“ исемендә чыгарыла.
**„Пионер каләме“** — 1933—1941 елларда Казанда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан чыгарылган балалар журналы; Ватан сугышы башлангач туктатыла һәм 1952 елдан „Пионер“ исемендә басыла башлый.
**„Совет мәктәбе“** — Казанда 1921—1936 елларда „Мәгариф“, 1936—1937 елларда „Башлангыч мәктәп“, 1938 елдан „Совет мәктәбе“ исемендә Татарстан Мәгариф министрлыгы тарафыннан чыгарыла торган педагогик һәм методик журнал; Ватан сугышы чорында туктатылып, 1949 елдан янадан чыга башлады.
**„Совет әдәбияты“** — 1932—1965 елларда Казанда чыккан әдәби һәм иҗтимагый-политик журнал; татар мәдәнияте һәм мәгарифе тарихыннан да мәкаләләр басылган; 1930—1932 елларда „Атака“, 1965 елдан соң „Казан утлары“ исемендә чыга.
**„Сугышчан алласыз“** — 1925—1937 елларда Мәскәүдә Сугышчан алласызларның Бөтенсоюз җәмгыяте Үзәк Советы тарафыннан чыгарылган татарча атеистик журнал.
**„Сөембикә“** — 1913—1918 елларда Казанда чыккан хатын-кызлар журналы; бала тәрбиясенә зур урын бирелгән.
**„Татар педагогия җәмгыяте хәбәрләре“** — 1928—1930 елларда Казанда чыккан педагогик журнал.
**„Татарстан“** — 1929—1931 елларда Казанда Татарстан гыйльми-тикшеренү экономика институты һәм Татарстанны өйрәнү җәмгыяте тарафыннан чыгарылган айлык журнал; мәктәпләр һәм анда укыту тәрбия эшенең торышы турында мәкаләләр бар.
**„Татарстан большевигы“** — 1932—1941 елларда, „Җитәкче“ журналының дәвамы буларак, Казанда ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан чыгарылган иҗтимагый-политик журнал; тәр-

бия мәсьәләләренә караган мәкаләләр дә басылган. Ватан сугышы башлангач туктатылган һәм 1958 елдан „Татарстан коммунисты" исемендә чыга башлаган.

**„Татарстан коммунисты"** — 1958 елдан Казанда чыга башлаган иҗтимагый-политик журнал.

**„Тәрбия"** — 1908 елда хатын-кызлар өчен Казанда чыгарылган педагогик журнал.

**„Тәрбия әл-этфаль"** — 1907 елда Мәскәүдә татарча чыккан беренче балалар журналы.

**„Уку ударнигы"** — 1937 елда Казанда чыккан педагогик журнал.

**„Укучы сәхифәсе"** — 1929—1931 елларда Казанда чыккан балалар журналы.

**„Укытучы"** — 1918 елда Казанда чыккан педагогик журнал (7 сан чыга).

**„Уралда мәгариф"** — 1923—1931 елларда Свердловскида чыккан педагогик журнал.

**„Урта мәктәптә тарих"** — 1935 елда Казанда чыккан методик журнал.

**„Фән һәм дин"** 1925—1932 елларда Мәскәүдә чыккан фәнни-популяр журнал; атеистик тәрбия мәсьәләсенә зур урын бирелә.

**„Чүкеч"** — 1906—1909 елларда Оренбургта чыгарыла, тәрбия һәм әхлак темаларына материаллар бар.

**„Шура"** — 1908—1917 елларда Оренбургта чыккан, педагогика һәм мәктәп проблемаларын киң яктырткан журнал.

**„Шәрык кызы"** — 1918 елда Казанда чыгарылган хатын-кызлар журналы.

**„Якты юл"** — 1920—1921 елларда Вяткада чыгарыла, мәгариф эшенең торышын яктырткан мәкаләләр бар.

**„Ялкын"** — 1957 елда Казанда ВЛКСМның өлкә комитеты тарафыннан чыгарыла башлаган балалар журналы; 1933—1941 елларда „Пионер каләме", 1952—1956 елларда „Пионер" исемендә чыга (Ватан сугышы елларында тукталып тора).

**„Яшь педагог"** — 1926—1929 елларда Казанда Көнчыгыш педагогия институты чыгарган педагогик журнал.

**„Яңа юл"** — 1921 елда Екатеринбургта чыга, уку-укыту мәсьәләләренә һәм мәктәп тормышына караган мәкаләләр бар.

**„Яңалиф"** — 1927—1930 елларда Казанда „Яңалифчеләр" җәмгыяте чыгарган.

**„Яңалифче"** — 1929 елда Новосибирскида чыга.

**„Әл-гасыр әл-җәдит"** — 1906 елда Казанда чыгарылган, мәктәптә яңача укыту мәсьәләләрен яктырткан журнал.

**„Җитәкче"** — 1925—1932 елларда Казанда чыккан иҗтимагый-политик журнал, 1932 елдан „Татарстан большевигы" исемендә чыга башлый.